РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРАЗМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРАЗМӘТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

*423986, РТ, Муслюмовский район, с.Уразметьево, ул.Школьная, 45а*
*тел. (8-85556) 3-22-22*


Үрәзмәт авылы "15 " март 2019 ел

# КАРАР № 2

**2019 елгы язгы ташу чорына Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау чаралары турында**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл жирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 7 маддәсе нигезендә 2019 елгы язгы ташу чорында халыкны, хужалык һәм торак объектларын, юлларны һәм күперләрне саклауны кисәтү максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Үрәзмәт авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Үрәзмәт авыл җирлеге территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия төзү.
2. Үрәзмәт авыл җирлеге территориясендә 4 кешедән торган гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясен төзергә һәм 2019 елгы язгы ташу чорында Үрәзмәт авыл җирлеге халкын һәм территориясен саклау буенча чаралар планын расларга.
3. Үрәзмәт авыл җирлеге гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерүне һәм икътисад объектларының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясенә тәкъдим итәргә:
   - Үрәзмәт авыл жирлегенең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм янгын куркынычсызлыгы, язгы ташуга каршы комиссия утырышларында икътисад объектларының куркынычсызлыгы, язгы ташу суларының авариясез үтүен тәэмин итү мәсьәләләрен карарга;
   - язгы ташу күренешләре аркасында килеп чыккан гадәттән тыш хәлләргә игътибар бирү һәм авария-торгызу эшләрен үткәрүгә җәлеп ителә торган көч һәм чаралар группировкасын ачыклау. Көч һәм чаралар турында мәгълүматлар җыю һәм гомумиләштерү, аларның гамәлләрен тикшереп тору;
   - елга һәм буаларда, саркофагларсыз үләт базлары янында су дәрәҗәсен тәүлек буе күзәтү өчен вакытлыча постлар оештырырга; - язгы ташуга каршы чаралар оештыруны тәэмин итү;
   - язгы ташу белән бәйле гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен халыкка җиткерүне тәэмин итәргә;
   - халыкны һәм территорияләрне язгы ташуның тискәре нәтиҗәләреннән саклау буенча чараларның үткәрелүен контрольдә тотуны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Үрәзмәт авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Закирянов Ә.Г.**

Мөслим муниципаль районы
Үрәзмәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенең
«15» март, 2019 ел,
5 нче санлы Карарына
1нче кушымта

## Үрәзмәт авыл җирлеге буенча гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүне тәэмин итү комиссиясе

1. Закирянов Әлфир Галимянович
2. Ахмадуллина Лилия Ханиповна
3. Арсланов Алмаз Мирхазиянович
4. Шакирова Алсу Ахматфатиховна

**Үрәзмәт авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Закирянов Ә.Г.**